**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Козяково-Челнинского**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
Иванова ул., дом 26,
с.Козяково-Челны, 422668

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Казак-Чаллысы**
**авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**
Иванов урамы, 26нчы йорт,
Казак-Чаллысы авылы , 422668

Тел.: (8-4361) 32-310 факс: (8-4361) 32-310, эл.адрес: Kcn.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 январь 2021 ел Казаклар Чаллысы авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының 2021 елның 13 гыйнварындагы “2021 елның 1 февраленнән Россия Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индексацияләү турында”гы СЧ-25-24/270 номерлы хатына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6424,98 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә, 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы 07.05.2019 елның № 10 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл(шәһәр) җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 нчы йорт; Иванаево авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы И.С.Ананьев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2021 елның 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә җирләү буенча 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча хезмәт күрсәтү бәясе**

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк- яракларны бирү һәм китерү | 1966 |
| 3. Мәетне (гәүдә калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 975 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү), кремацияләнгән мәет калдыклары | 3483,98 |
| Барлыгы: | 6424,98 |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.01.2021 елның 1 карары буенча 2 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирләү буенча Казаклар Чаллысы авыл җирлегендә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә үлгән затның законлы вәкиле булмаганда яисә җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә алган бүтән зат булмаганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 542 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 1424 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәд калдыкларын) зиратка илтү | 975 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3483,98 |
| Барлыгы | 6424,98 |